Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Татар Ялтаны авыл җирлеге Советының
карары

2022 елның 29 марты № 20/1

«Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Татар Ялтаны авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирле бюджеты акчалары исәбеннән инвестиция проектлары буенча муниципаль гарантияләр бирү тәртибен раслау турында» 2020 елның 23 июлендәге 81/3 номерлы Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Татар Ялтаны авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Татар Ялтаны авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Татар Ялтаны авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирле бюджеты акчалары исәбеннән инвестиция проектлары буенча муниципаль гарантияләр бирү тәртибен раслау турында» 2020 елның 23 июлендәге 50/3 номерлы карарына Чистай шәһәр прокурорының 2022 елның 4 мартындагы 02-08-02-2022 номерлы протестын карап, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Татар Ялтаны авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Татар Ялтаны авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Татар Ялтаны авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирле бюджеты акчалары исәбеннән инвестиция проектлары буенча муниципаль гарантияләрне бирү тәртибен раслау турында» 2020 елның 23 июлендәге 81/3 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Татар Ялтаны авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирле бюджеты акчалары исәбеннән инвестиция проектлары буенча муниципаль гарантияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.2.1 пунктында «Физик затны индивидуаль эшкуар буларак дәүләт теркәве турында таныклык күчермәсе (индивидуаль эшкуарлар булган принципаллар өчен)» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2. 2.2.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2.2. Мөрәҗәгать итүче үз инициативасы белән түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә хокуклы:

1) муниципаль гарантия бирү турында гариза бирелгән көнгә кадәр 30 көннән дә иртәрәк булмаган вакыт эчендә салым органының салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, оешмалар һәм индивидуаль эшкуарлар процентлары турында белешмәсе;

2) бухгалтерлык балансы (ОКУД 0710001 формасы);

3) финанс нәтиҗәләре турында хисап (ОКУД 0710002 формасы);

4) аңлатма язуы (муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләр өчен Финанс министрлыгының "Дәүләт (муниципаль) бюджет һәм автоном

учреждениеләрнең еллык, квартал бухгалтерлык хисаплылыгын төзү, тапшыру тәртибе турында инструкцияне раслау турында" боерыгы нигезендә, калганнары өчен - үрнәк форма);

5) иң эре дебиторлар һәм кредиторлар күрсәтеп, бухгалтерлык балансы буенча (бурычның һәр төре буенча) дебитор һәм кредит бурычларын расшифровкалау (бурычларның гомуми суммасыннан 5 %тан артык) һәм бурыч барлыкка килү датасы;

6) соңгы ике елда алынган муниципаль берәмлек бюджеты акчаларыннан максатчан файдалану турында мәгълүмат (мондый хәл булган очракта);

7) принципалның бухгалтерлык хисабының дөреслеге турында аудиторлык бәяләмәләре (Россия Федерациясе законнары нигезендә ел саен аудиторлык тикшерүе узарга тиешле юридик затлар өчен);

8) соңгы ике тәмамланган финанс елына салым декларацияләренең (шундый булса) муниципаль гарантия алуга гариза биргән көнгә кадәрге күчермәләре;

9) физик затны индивидуаль эшкуар буларак дәүләт теркәве турында таныклык күчермәсе (индивидуаль эшкуарлар булган принципаллар өчен).

Әлеге пунктның 2-7 бүлекләрендә күрсәтелгән документлар алдагы елда, агымдагы финанс елының соңгы хисап чорына һәм Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган рәвешләр буенча алдагы елның шул ук чорына бирелә.»;

1.3. 2.3., 2.4., 2.21 пунктларын төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында (http://chistopol.tatarstan.ru/) урнаштырырга.

Татар Ялтаны авыл җирлеге
башлыгы Р.Р. Гарифуллин